РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
НУРЛАТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НОРЛАТ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

19 октябрь 2022 ел № 1-58

Карарны гамәлдән чыгару турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 һәм 15 статьялары, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлекләрендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 22 ноябрендәге 2-21 номерлы карары (2022 елның 28 февралендәге 1-25 номерлы карары редакциясендә), Норлат авыл җирлеге Уставы нигезендә, Буа муниципаль районы Норлат авыл җирлеге Советы карары

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Буа муниципаль районының Норлат авыл җирлеге Советының «Буа муниципаль районы Советының төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советына тапшыру турында» 2022 елның 23 сентябрендәге 1-57 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http://buinsk.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

ТР Буа муниципаль районының
Норлат авыл җирлеге башлыгы М.Х. Закиров